СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**карары**

**“18” июль 2023 ел** **№77**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына ярашлы рәвештә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 23.04.2021 ел, № 19 (03.10.2022 ел, № 59 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 19 статьяның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл старостасы аның составына әлеге авыл җирлеге кергән авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә. Авыл старостасы әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнгә 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл җирлеге территориясендә урнашкан торагы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

2) 19 статьяның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Авыл старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче зат була алмый, муниципаль берәмлекнең даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан яисә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш, җирле үзидарә

органнары белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм алар белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә тора алмый.»;

3)19 статьяның 4 нче пунктының 1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче, муниципаль вазыйфа, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш;»;

4) 32 статьяның 8 һәм 9 пунктларында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен "Татарстан Республикасы Башлыгы" (Рәисе) сүзләренә алыштырырга;

5) 32 статьяның 10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

6) 42 статьяны 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

«6. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән, әгәр депутат җитди сәбәпләрсез муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышларында алты ай рәттән булмаса, вакытыннан алда туктатыла.»;

7) 68 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 68.1 статья белән тулыландырырга:

"68_1 статья. Торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең эчтәлеге

1. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре җирлек Советы тарафыннан раслана.

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре:

1) гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм мондый территорияләрдән файдалану тәртибе;

2) биналарның, корылмаларның фасадларының һәм саклагыч конструкцияләренең тышкы күренеше;

3) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу, шул исәптән җир эшләре үткәрелгәннән соң;

4) җирлек территориясен яктыртуны оештыру, биналарны, корылмаларны, архитектур яктыртуны кертеп;

5) җирлек территориясен яшелләндерүне оештыру, шул исәптән торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннарны, чәчәк бакчаларын һәм үлән үсемлекләре үскән башка территорияләрне булдыру, карап тоту, торгызу һәм саклау тәртибен;

6) мәгълүматны җирлек территориясендә урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр, элмә такталар урнаштыру;

7) балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларны, парковкаларны (машина кую урыннарын), кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту;

8) җәяүлеләр коммуникацияләрен оештыру, шул исәптән тротуарлар, аллеялар, юллар, сукмаклар;

9) күрсәтелгән территория буенча инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү максатыннан торак пункт территориясен төзекләндерү;

10) җирлек территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда;

11) яңгыр суларын агызуны оештыру;

12) җир эшләрен башкару тәртибе;

13) биналарның, корылмаларның, җир кишәрлекләренең милекчеләре һәм (яки) башка законлы хуҗаларының (алар астында җир кишәрлекләре барлыкка килмәгән яки

мондый йортлар чикләре буенча төзелгән күпфатирлы йортлардагы милекчеләрдән һәм (яки) башка законлы милекчеләрдән тыш) янәшәдәге территорияләрне карап тотуда катнашуы;

14) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә янәшәдәге территорияләр чикләрен билгеләү;

15) җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү;

16) җирлек территориясен төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыруда ґражданнар һәм оешмаларның катнашу тәртибе.»;

8) 81 статьясының 7 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча иҗтимагый хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар;»;

9) 83 статьясының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25_1 статьясының 1 өлешендәге 4, 4_1 һәм 4_3 пунктларында каралган очракларда, гражданнар җыенында хәл ителә.».

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга .

5. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1) Мифтәхетдинов Рәвис Шәрәфи улы -4 нче Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2) Миндубаев Тәлгәт Җәүдәт улы -9 нчы Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Заһидуллин Фаил Нурулла улы – 2 нче Яңа Кырлай сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

6. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутатларының уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына тәкъдимнәрен һәм төзәтмәләрен эшче төркемгә 2023 елның 16 августына кадәр кертелә дип билгеләргә.

7. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына гражданнарның тәкъдимнәре авторның исем-фамилиясе, туган елы, адресы күрсәтелеп, эшче төркемгә ТР, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

8. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны 2023 елның 17 август 16.00 сәгатьтә Яңа Кырлай авыл мәдәният йорты бинасында билгеләргә.

9. Эшче төркемгә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны 2023 елның 17 сентябренә кадәр Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Д.З.Абдуллин

Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының
18 июль 2023 ел, № 77
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге уставы проекты буенча тәкъдимнәр язмача төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына 422035, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Проектның төзәтмә кертелгән тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и.,адресы, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу турында гаризалар язма рәвештә яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 422035, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына һәм башлыгына карау өчен тапшырыла.

Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының
18 июль 2023 ел, № 77
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру

# ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы проектын карау буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставының 22 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте, прокуратура органнары, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, белгечләр, кызыксынган затларны чакырып үткәрелергә мөмкин.

3.Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегендә яшәүче һәркем катнашырга хокуклы.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы яки башлык урынбасары рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән устав проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе чыгыш ясый.

9. Төп докладтан соң сүз гавами тыңлауларда катнашырга чакырылган катнашучыларга бирелә.

10. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар рәис рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга чыгыш ясаганнан соң сораулар бирергә хокуклы.

13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Гавами тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар үткәрелә торган бинадан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә җитәкче һәм секретариат әгъзалары имза сала һәм ул Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Гавами тыңлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.